# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Үтәгән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

23.10.2020 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Үтәгән торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2020 елның 23 октябрендә 10 сәгать 30 минутта уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Үтәгән торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм ирекtән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- Үтәгән авылында Үзәк урамы, Дуслык урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Үтәгән авылында урам яктырткычлары сатып алу, диодлы лампалар кую, килешү буенча эшләр өчен түләү;

- Үтәгән авылында халыкны су белән тәэмин итүне тоту (су җыю системасының өзеклеген бетерү, экскаваторны арендага алу шартнамәсе буенча түләү, тирәнлек насослар һәм материаллар сатып алу);

- юлларга хезмәт күрсәтү - Үтәгән авылындагы урамнарны кардан чистарту (трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Үзәк урам буенча күперне ремонтлау (пиломатериаллар сатып алу һәм подрядчыларга түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 163 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 84 кеше, бу 51,5 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 84 катнашучы тавыш бирде;
"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Үтәгән торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Үтәгән торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Үтәгән авылында Үзәк урамы, Дуслык урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Үтәгән авылында урам яктырткычлары сатып алу, диодлы лампалар кую, килешү буенча эшләр өчен түләү;

- Үтәгән авылында халыкны су белән тәэмин итүне тоту (су җыю системасының өзеклеген бетерү, экскаваторны арендага алу шартнамәсе буенча түләү, тирәнлек насослар һәм материаллар сатып алу);

- юлларга хезмәт күрсәтү - Үтәгән авылындагы урамнарны кардан чистарту (трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Үзәк урам буенча күперне ремонтлау (пиломатериаллар сатып алу һәм подрядчыларга түләү).

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы — И.Н. Гафаров

Совет Старосляковского сельского поселения / Иске Эсләк авыл җирлеге Советы / Агрызский муниципальный район Республики Татарстан / Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы / ИНН 1601002580